РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 45 2023 елның 10 августы

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 статьяда:

12.5 пунктта «муниципаль хезмәтнең» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

12.7 пунктта «муниципаль хезмәтнең» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

12 статьяның 12.8 пунктында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 13 статьяның 13.1 пунктындагы 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 14 статьяда:

14.7 пунктта «дөрес булмаган яки» сүзләрен төшереп калдырырга, «муниципаль хезмәтнең» сүзләреннән соң «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 14.7.1 пункты белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан әлеге статьяның 14.7 пунктында күрсәтелгән күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

14.8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләре белән алыштырырга;

14.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләре белән алыштырырга;

14.11 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

4) 16 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 16.6 пункт белән тулыландырырга:

«16.6. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрү буенча Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;

5) 17 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 17.7 пункт белән тулыландырырга:

«17.7. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә үткәрелә.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы — Р.Х. Муллин